**Класс:** 5

**Укытучы:** Шакирова Рузилә Рәисовна

**Программа:** Вигасин А.А. Гомуми тарих. Борынгы заман тарихы. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.

**Тема:** Борынгы Спарта

**Максаты**: Укучыларны Спарта полисы һәм тәрбиясе белән таныштыру; укучыларда тарих фәненә кызыксыну тәрбияләү

**Планлаштырылган нәтиҗә:** яңа терминнарны үзләштерү.

**I. Лекция.**

**Исәнмесез, укучылар! Бүгенге темабыз “Борынгы Спарта”- дип атала. Спарта полисы үзенең көчле армиясе һәм тәрбиясе белән башка полислардан аерылып торган. Дәрес барышында түбәндәге бүлекләргә тукталырбыз:**

- Спарталылар һәм илотлар
- Спарта - хәрби лагерь
- Спарта тәрбиясе

**(2 слайд)** (Спарта өстендә мигать итсен) Спарталыларның бабалары Балкан ярымутравының төньягыннан килеп Көньяк Грециядә нигезләнгән грек кабиләләре булган. Еврот елгасы үзәнендәге Лакония өлкәсендә берничә күрше биләмә берләшә һәм Спарта дип атала башлый.

Спарталылар, акырынләп, бөтен Лаконияне буйсындыралар, аның халкын үзләренә эшләргә мәҗбүр итәләр һәм аларны илотлар дип атап йөртәләр.

**(3 слайд) Илот -** грекча басып алынганнар дигәнне аңлата. Лакония янында уңдырышлы җирле Мессения өлкәсе урнашкан. Спарталылар рәхимсез сугыштан соң бу өлкәне дә басып алалар. Мессения кешеләре дә илотларга әйләнә.

Спарталылар Лакония һәм Мессения җирләрен тигез итеп үзара бүләләр. Бу җирләрдә илотлар эшли. Үстерелгән иген, зәйтүн, яшелчә уңышының һәм

башка азык- төлекнең зур гына өлешен алар спаталыларга бирәләр. *Илотлар Спарта дәүләтенең коллары булалар, аларга үз авылларын ташлап китү тыела*.

**Укучылар сез ничек уйлыйсыз, илотларга карата нинди мөнәсәбәт булган икән? (4 слайд)** Спарталылар илотлар белән бик тупас һәм рәхимсез мөгамәлә иткәннәр. Мәсәлән, илотларны су кушылмаган шәраб эчәргә мәҗбүр итәләр, аннары аларны, эчкечелеккә нәфрәт уяту өчен, яшьләргә күрсәтәләр.

Лакониядә һәм Мессениядә илотлар халыкның күпчелеген тәшкил иткән. Аларның баш күтәрүеннән куркып, спарталылар коралсыз кешеләрне кыйный торган булганнар. Яшүсмерләрне, кулларына кылыч тоттырып, тирә-юньгә йөрергә чыгарганнар. Көндез алар качып торганнар, ә төннәрен юлларында очраган илотларны үтергәннәр. Еш кына ул яшьләр, кырларда йөреп, иң көчле илотларны да һәлак иткәннәр. **Әлеге гамәлләрне башка халыклар ничек бәяләгән икән соң?**

**(5 слайд)** Грециянең башка халкы илотларны шулай җәберләүне кабахәтлек дип санаган һәм үз кешеләрен – грекларны коллыкта тотучы спарталыларны гаепләгән.

Спартаның ныгытылган диварлары булмаган. **(6 слайд)** Халык шәһәрнең бердәнбер ышанычы сакчысы булып таш түгел, ә кыю ирләр тора дигән. Спарталыларның төп шөгыле хәрби эш була, Спарта пехотасы Грециядә иң яхшы гаскәр санала**.( 7 слайд) Укучылар, спарталылар ни өчен сугышка кызыл төстәге кием кигәннәр икән?** Беренчедән кызыл төсне алар чын ир-егетләр төсе дип санаганнар. Икенчедән тәҗрибәсе булмаган дошман солдатларында курку уяту өчен. Яраланган солдатларның аккан канын дошманнан шул кызыл төс яшереп калырга да тиеш булган.

**(8 слайд)** Спарта беркемгә дә үзе теләгәнчә яшәргә рөхсәт ителми торган хәрби лагерьны хәтерләткән. Спарталыларга сәүдә һәм һөнәрләр белән шөгыльләнү тыелган, һәртөрле кул эшенә җирәнеп каралган.

Спартага чит илләрдән килүче булмаган. Биредә бернәрсә дә сатмаганнар, сокланырлык нәрсә булмаган: шәһәрдә матур биналар төзелгән, таш сыннар ясалган. Спартада яшәүчеләрне, башкаларның тормышына кызыкмасыннар дип, чит илләргә чыгудан тыйганнар.

**(9 слайд)** Өйдә ашау да тыелган. Спарта ирләре, унбишәр кешелек төркемнәргә берләшеп, һаман да шул бер төрле ризык – сыек аш, яшелчә, бераз сыр, сирәк кенә ит һәм балык ашый торган булганнар. Бервакыт Спартага җиңүдән соң атаклы гаскәр башлыгы кайта. Ул, бу юлы хатыны белән бергә ашарга теләп, үзенә ризыкны өенә китерергә куша. Тик аның кушканын үтәүче булмый, алай гына да түгел, аны хәтта штрафка тарталар.

**(10 слайд)** Бу кагыйдәләрнең үтәлешен чикләнмәгән хакимияткә ия булган *Аксакаллар шурасы* күзәткән. Шурага яше 60 тан да ким булмаган иң лаеклы кешеләрне керткәннәр. Алар аның утырышларында гомеренең соңгы көненәчә катнашканнар.

**(11 слайд)** Спарта ирләреннән генә торган *Халык җыелышы,* аксакаллар сайлаудан тыш, сугыш игълан итү һәм тынычлык урнаштыру буенча да хәлиткеч сүзне әйткән. Җыелышта чыгыш ясау хокукына аксакаллар гына ия булган. Калганнар “әйе” яки “юк” дигән тәгъдимнәрен генә кычкырып белдерә алганнар.

**(12 слайд)** Гаскәр белән ике башлык җитәкчелек иткән, аларны *патшалар* дип атаганнар. Патшалар хакимияте буыннан буынга күчеп килгән, ләкин зур булмаган. Патшалар Аксакаллар шурасына кергәннәр һәм гадәттә аның ихтыярына берсүзсез буйсынганнар.

Б.э.к. VI (6 нчы) гасырда Спарта Грециянең иң кодрәтле полисларының берсенә әверелгән.

Греклар Спартада балалар ата-аналарныкы түгел, ә дәүләтнеке дип исәпләгәннәр. **(13 слайд)** Ата кеше үзенең яңа туган баласын аксакаллар янына китергән. Тегеләр баланы таза һәм нык дип тапсалар, атасына кире кайтарганнар. Әгәр дә чирләшкә икән, аны тау башыннан упкынга ташлаганнар.

**(14 слайд**) Җиде яше тулган малайларны, ата-аналарыннан алып, отрядларга биргәннәр. Алар анда бергә яшәгәннәр һәм ашаганнар. Һәр отрядның башына зирәклеге белән аерылып торган, сугышканда калганнардан кыюрак булган кешене куйганнар. Башкалар аның боерыкларын үтәгәннәр һәм җәзаларына сүзсез түзгәннәр.

Иң хөрмәтле спарталыларның берсе малайларның төп тәрбиячесе итеп билгеләнгән. **(15 слайд)** Малайларның уенын картлар күзәтеп торган. Алар, төрлечә котыртып, малайлар арасында ызгыш-талаш һәм сугыш китереп чыгарырга тырышканнар һәм кайсының ничек сугышуын, җитезлеген күзәткәннәр.

**(16 слайд)** Малайларны авырлыкларга түзәргә өйрәткәннәр. Аларның чәчләрен кыска итеп кискәннәр, ярымшәрә һәм яланаяк йөрткәннәр; алар Еврот ярларыннан ялан куллары белән быеп алган камыштан үзләре үк үргән көрпәгә ятып йоклаганнар.

Малайларны, үзләре өстәмә ризык тапсыннар өчен, бик саран ашатканнар. Алар яшелчә бакчаларын басканнар, кеше амбарларын, хәтта храмнардан аллаларга корбан итеп китерелгән ризыкны талап алганнар. Ашый торган бөтен әйберне – икмәк, сыр, яшелчәне – каравылчының борын астыннан урлап китә торган булганнар.Ләкин карак эләксә, аны чыбык белән кыйнаганнар.

Яшь спарталыларны кыска итеп сөйләргә, тапкыр һәм төгәл җаваплар бирергә өйрәткәннәр (андый сөйләм Лакония өлкәсенең исеме буенча *лаконияле сөйләм* дип аталган).

**(17 слайд)** Афиналылар спарталыларны томаналар дип атаганнар, чөнки анда малайларны бик аз укытканнар. Аның каравы алар бик тырышып гимнастика белән шөгыльләнгәннәр: йөгерү, сикерү, тәлинкә һәм сөңге ыргыту буенча ярышлар үткәргәннәр. Алар, флейтага кушылып, сәгатьләр буе хәрби җырлар өйрәнгәннәр. Шушы җырларны җырлап сугышка барганнар. Бу җырларда алар Спарта өчен һәлак булучыларны мактаганнар,

куркакларга ләгънәт укыганнар, киләчәктә үзләре дә гасырлар буе онытылмаслык батырлыклар эшләргә вәгъдә биргәннәр.

**II практик эш**

**Беренче бирем**

Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| **Аңлатма** | **Термин** |
|---|---|
| | Грекча басып алынганнар |
| | Грециядә гаскәр белән җитәкчелек итүче |
| | Кыска, тапкыр, төгәл җавап бирү |

**Җаваплар:**

Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| **Аңлатма** | **Термин** |
|---|---|
| илот | Грекча басып алынганнар |
| патша | Грециядә гаскәр белән җитәкчелек итүче |
| Лаконияле сөйләм | Кыска, тапкыр, төгәл җавап бирү |

**Икенче бирем**

Төшеп калган сүзләрне языгыз.

___________ чит илләрдән килүче булмаган. Бирегә бернәрсә дә сатмаганнар, сокланырлык нәрсә булмаган: __________ матур _________ төзелгән, таш сыннар ясалган. Спартада яшәүчеләрне, башкаларның _______ кызыкмасыннар дип, чит илләргә чыгудан тыйганнар.

Сүзләр: *шәһәрдә, Спартага, тормышына ,биналар.*

**Җавап:**

***Спартага*** чит илләрдән килүче булмаган. Бирегә бернәрсә дә сатмаганнар, сокланырлык нәрсә булмаган: ***шәһәрдә*** матур ***биналар*** төзелгән, таш сыннар

ясалган. Спартада яшәүчеләрне, башкаларның ***тормышына*** кызыкмасыннар дип, чит илләргә чыгудан тыйганнар.

**Өченче бирем**

**Дөрес өч җавапны сайлагыз.**

- Спарталыларга сәүдә һәм һөнәрләр белән шөгельләнү тыелган;
- Малайларны бик иркен ашатканнар;
- Малайларны авырлыкка түзәргә өйрәткәннәр;
- Спарталыларга чит илләрдән килүче күп булган;
- Гаскәр белән бер башлык җитәкчелек иткән;
- Җиде яше тулган малайларны, ата-аналарыннан алып, отрядларга биргәннәр.

**Дөрес җавап:**

- Спарталыларга сәүдә һәм һөнәрләр белән шөгыльләнү тыелган;
- Малайларны авырлыкка түзәргә өйрәткәннәр;
- Җиде яше тулган малайларны, ата-аналарыннан алып, отрядларга биргәннәр.

**Дүртенче бирем**

***Борынгы Спарта тәрбиясен хәтерегезгә төшерегез.*** Ул болай башлана: Җиде яше тулган малайларны, ата – аналарыннан алып, отрядларга биргәннәр. Алар анда ..... .

Малайларның тәрбиясе ничек барган? Анда аларны кем тәрбияләгән? Хикәя төзегәндә, рәсемдә сурәтләнгәннәрдән дә файдаланыгыз.



